Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге Шыгай авыл
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» ноябрь 2019 ел. № 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегендә Шыгай авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә 2019 елның 14 ноябрендә үзара салым мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. “I нче группа инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәренән, көндезге бүлек студентларынан, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Азалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 2020 елда үзара салым акчасын 200 сум күләмендә кертүгә килешәсезме?”. Һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрү турында Карар кабул ителде:

- Шыгай авылы урамнарнарына яктырту лампалары сатып алу һәм урнаштыру;
- Шыгай авылында (Сабантуй, 9 Май, Яңа ел, өлкәннәр көне, инвалидлар көне) бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- Шыгай мәдәният йорты өчен Кыш Бабай һәм Кар кызы костюмнары һәм ясалма чыршы сатып алу;
- Шыгай авылы зиратлар өчен бензокосилки сатып алу
- Шыгай авылында кышкы чорда юлларны кардан чистарту;
- төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтүчеләргә түләү (Шыгай авылы территориясендә үлән чабу)
- ГАЗ-САЗ-3512 автомашинасы һәм бензокосилка өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу:

"ӘЙЕ” “ЮК”.

14.11.2019 елдагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 125 кеше, гражданнар җыенында катнашучылар саны 72 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 72 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегендә, Сарман муниципаль районы Шыгай авылында узган халык җыенын халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. "I нче группа инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәренән, көндезге бүлек студентларынан, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Азалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 2020 елда үзара салым акчасын 200 сум күләмендә кертүгә килешәсезме, һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү турында карар кабул ителгән дип танырга («әйе»- 72, «юк» - 0).:

- Шыгай авылы урамнарнарына яктырту лампалары сатып алу һәм урнаштыру;
- Шыгай авылында (Сабантуй, 9 Май, Яңа ел, өлкәннәр көне, инвалидлар көне) бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- Шыгай мәдәният йорты өчен Кыш Бабай һәм Кар кызы костюмнары һәм ясалма чыршы сатып алу;
- Шыгай авылы зиратлар өчен бензокосилки сатып алу
- Шыгай авылында кышкы чорда юлларны кардан чистарту;
- төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтүчеләргә түләү (Шыгай авылы территориясендә үлән чабу)
- ГАЗ-САЗ-3512 автомашинасы һәм бензокосилка өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу:

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http//sarmanovo.tatar.ru һәм Шыгай авылы, Шоссейная урамы, 18А йорты адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.Г.Габдулгазизов